ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 19 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта, торак урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне региональ оператор тарафыннан үз көче яисә өченче затлар көче белән бирелгән түләү документлары нигезендә торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүне кертү өчен Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән срокларда түлиләр.»;

2) $2^1$ өлештә «торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү билгеләнгән» сүзләрен «торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүне кертү өчен Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 22-ТРЗ